МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.08.2014 № 246-ОД

г. Казань

**Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының “Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында”гы 2013 елның 8 июлендәге 191–ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79–ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында”гы 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының “Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында”гы 2013 елның 8 июлендәге 191–ОД номерлы боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

боерыкның атамасын түбәндәге редакциядә бирергә:

“Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында”;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының “Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында”гы борык белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә):

Нигезләмәнең атамасын түбәндәге редакциядә бирергә:

“Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында Нигезләмә”

1 бүлекчәнең 1.6 пунктның 1.6.3 подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

“1.6.3 Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында”гы 2004 елның 27 июлендәге 79–ФЗ номерлы Федераль Законның 60.1 матдәсенең 9 өлешендә һәм 31 матдәсенең 1 өлешендә, 28 матдәсенең 2 өлешендә каралган граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә”;

2 бүлекчәдә:

2.4 пункттагы “Татарстан Республикасы каршында дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча Департаменты вәкиле, шулай ук Татарстан Республикасы каршында дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча Департаменты тарафыннан чакырылган фән һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар” сүзләрен “Татарстан Республикасы Президенты каршында дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты вәкиле, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршында дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан чакырылган фән, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре” сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктта:

2.8.1 подпукттагы “конкурсны үткәрү шартларын регламентлаучы документлар,” сүзләрен алып ташларга;

2.8.4 подпукт үз көчен югалткан дип танырга;

2.11 пунктта:

“яки кадрлар резервына кертү,” сүзләрен алып ташларга;

түбәндәндәге абзац белән тулыландырырга:

“Конкурс комиссиясе шулай ук граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә уздырылган конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары

буенча югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итәргә хокуклы";

3 бүлекчәнең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

"3.2 әлеге Боерыкның 4 Кушымтасында күрсәтелгән документлар Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат–коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында аларны кабул итү турындагы игълан урнаштырылган көннән 21 көн эчендә министрлыкка тапшырыла";

4 бүлекчәдә:

4.4.4 подпунктта "Дәүләт органының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында" сүзләрен "Министрлыкның һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының "Интерне" мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында сүзләре белән алмаштырырыга";

"(3 Кушымтага Кушымта)" сүзләрен "(4 кушымтага кушымта)" сүзләре белән алмаштырырыга;

4.4.5 подпунктта "конкурста катнашу" сүзләреннән соң "карар кабул итүдән соң өч көн дәвамында" сүзләре белән тулыландырырга;

4.4.9 подпунктның икенче авзацында "е) структур бүлекчә һәм башка эшчәнлек юнәлешләре буенча норматив хокук актлары" сүзләрен "структур бүлекчә эшчәнлек юнәлешләре буенча норматив хокук актлары";

4.5 пунктның 5.5.2 подпунктта "5.5.2." саннарын "4.5.2." саннарына алмаштырырга;

4.9 пунктта ", яки граждан хезмәткәрен Министрлыкның башка төркем яки категориядәге дәүләт хезмәте вазыйфасына күчергәндә"

4.10 пунктта:

беренче абзацта "Министр Боерыгы" "министр боерыгы" сүзләре белән алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

“Әгәр конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын бтләүгә уздырылган кокурста җиңмәгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителә икән, күрсәтелгән затның рөхсәте белән, граждан хезмәте вазыйфасын биләү максатында аның Министрлыкның кадрлар резервының граждан хезмәтенең әлеге вакантлы вазыйфасы кергән төркеменә кабул ителүе турында боерык чыгарыла”;

4.11 пуктны түбәндәге редакциядә бирергә:

“4.11. конкурста катнашучы кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында язма формада конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә хәбәр ителә (Нигезләмәгә 8 кушымта). Конкурсның нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлыкның һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының “Интернет” мәгълүмат –телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла (Нигезләмәгә 9 кушымта)”;

Нигезләмәгә 3 кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

Нигезләмәгә 4 кушымтада:

атаманы түбәндәге редакциядә бирергә:

“Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурсында катнашу өчен документлар кабул ителүе турында игълан”;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

“6. Конкурста катнашу өчен Россия Федерациясе гражданы түбәндәге документлар тапшыра:

а) расланган форма буенча шәхси гариза (2013 елның 8 июлендәге Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 191–ОД номерлы боерыгы белән расланган Исемлеккә 1 кушымта);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган формасы буенча шәхси тутырылган һәм имзаланган фото белән анкетаны;

в) паспорт копиясен яки аны алмаштыра торган документ (документ конкурка килгәч шәхси күрсәтелә);

г) тиешле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торагн документлар:

нотариус яки эш хезмәт урынындагы кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсенең күчерелмәсе хезмәт эшчәнлеге (эше) беренче тапкыр алып барылу очракларыннан тыш) яки гражданның хезмәт эшчәнлеген (эшен) раслый торган башка документлар;

белем һәм квалификация турындагы документларның күчерелмәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәсе буенча квалификация бирелүне һәм күтәрүне раслый торган документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы нотариуч яки эш (хезмәт) урынындагы кадрлар хезмәте тарафыннан расланган документларның күчерелмәләре;

д) граждан хезмәтенә керешүгә яки аны үтәүгә каршы килә торган авыруларның гражданинда булмавын раслаучы документ;

е) Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында федераль законнарында каралган башка документлар.";

7 пунктның икенче абзацен алып ташларга;

Нигезләмәгә 9 кушымтасында "Министрлык боерыгы белән" сүзләрен "министрның боерыгы белән (Министрлык боерыгы)" сүзләре белән алмаштырырга;

Боерыкның 3 кушымтасында:

атаманы түбәндәге редакциядә бирергә:

"Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүче (кадрлар резервына кертү) кандидатларга карата таләпләр";

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

“1.2. Гражданин конкурста катнаша алмаган очраклар:

законлы көченә кергән суд карары белән аны эшкә сәләтсез яки эшкә чикләнгән дип таныганда;

законлы көченә кергән суд карары белән аны билгеле бер вакыт дәвамында дәүләт хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын биләү хокуыннан мәхрүм иткәндә;

дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне үз эченә алган мәгълүмат белән эшләүгә рөхсәтне рәсмиләштерү процедурасын үтәүдән баш тартканда, әгәр дәүләт хезмәтенең дәүләт вазыйфасы буенча граждан дәгъваланган вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматны файдалануга бәйле булса;

вазыйфаи бурычларын үтәүгә медицина учреждениясе бәяләмәсе белән расланган комачаулый торган авыруы булганда. Диспансеризация үтү тәртибе, шундый авыруларның исемлеге һәм медицина оешмасы бәяләмәсе формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән вәкаләтле башкарма хакимияте федераль органы тарафыннан билгеләнә;

әгәр хезмәтләре турыдан–туры буйсынуга яисә берсенең икенчесен тикшереп торуына бәйле булса, дәүләт хезмәткәре белән якын туган яисә үз кеше (ата–аналар, ир белән хатын, сеңелләр, уллар һәм кызлар, шулай ук ирнең яки хатынның абыйлары, сеңелләре, эти–әнисе һәм балалары) булганда;

Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкканда яки башка дәүләт гражданлыгын алганда;

башка дәүләт (башка дәүләтләр) гражданлыгына ия булганда, Россия Федерацияссе халыкара килешүендә башкача күздә тотылмаганда;

гражданлык хезмәтенә кергәндә ялган документлар яки белә торып ялган мәгълүматлар тапшырганда;

“Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79–ФЗ номерлы Федераль законы белән каралган гражданлык хезмәтенә кергәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырмаганда яки белә торып ялган мәгълүматлар тапшырганда;

чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр бәрелешен кисәтү яки җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, №79-ФЗ Федераль закон, “Коррупциягә каршы тору турында” 25 декабрь, 2008 ел, №273-ФЗ Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә коррупциягә каршы тору максатыннан чыгып билгеләнгән бурычларны үтәмәгән очракта эшкә яллаучының вәкиле тарафыннан гражданлык хезмәткәренә карата ышаныч югалганда;

хәрби чакырылыш комиссиясе бәяләмәсе нигезендә законлы нигезләргә ия булмыйча гына чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтмәгән дип танылганда (контракт буенча хәрби хезмәт иткән гражданнардан тыш).”;

2 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бирергә:

“2. Квалификация таләпләре

2.1 Белеменә һәм гражданлык хезмәте стажына яки эш стажына (тәҗрибә) карата квалификация таләпләре.

“Гражданлык хезмәте вазыйфаларының “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)”, “белгечләр” категорияләренә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларына, шулай ук гражданлык хезмәте вазыйфаларының төп һәм әйдәп баручы төркемнәренең “тәэмин итүче белгечләр” категориясенә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларына карата квалификация таләпләре исәбенә югары белемгә ия булу кирә.

Гражданлык хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренең “тәэмин итүче белгечләр” категорияләренә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларына карата квалификация таләпләре исәбенә эшчәнлек юнәлешенә туры килүче урта һөнәри белемгә ия булу кирә.

Гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына (тәҗрибә), гражданлык хезмәткәрләренең әзерләнү юнәлешенә түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

гражданлык хезмәте вазыйфаларының төп төркеменең барлык категорияләренә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – әйдәп баручы яки өлкән төркемдәге гражданлык хезмәте вазыйфаларында кимендә ике

еллык гражданлык хезмәте стажы яки белгечлек, әзерләнү юнәлеше буенча кимендә өч еллык эш стажы;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең барлык категорияләренә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – өлкән яки кече төркемдәге гражданлык хезмәте вазыйфаларында кимендә бер еллык гражданлык хезмәте стажы яки белгечлек буенча, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажы;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, (тәҗрибә), әзерләнү юнәлешенә карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Гражданлык хезмәте стажын билгеләгәндә тиешле вазыйфаи төркемнәрдә федераль дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тигезләштерелгән хәрби һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларында, шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларында эшләү стажы да исәпкә алына.

2.2. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре гражданлык хезмәтенең вазыйфаи регламенты нигезендә билгеләнгән."

Боерыкның 4 кушымтасын түбәндәге редакциядә бирергә:

"Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертү) кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы түбәндәге документлар тапшыра:

а) расланган форма буенча шәхси гариза (2013 елның 8 июлендәге Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 191–ОД номерлы боерыгы белән расланган Исемлеккә 1 кушымта );

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган формасы буенча шәхси тутырылган һәм имзаланган фото белән анкетаны;

в) паспорт копиясен яки аны алмаштыра торган документ (документ конкурка килгәч шәхси күрсәтелә);

г) тиешле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торагн документлар:

нотариус яки эш хезмәт урынындагы кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсенең күчерелмәсе хезмәт эшчәнлеге (эше) беренче тапкыр алып барылу очракларыннан тыш) яки гражданның хезмәт эшчәнлеген (эшен) раслый торган башка документлар;

белем һәм квалификация турындагы документларның күчерелмәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәсе буенча квалификация бирелүне һәм күтәрүне раслый торган документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы нотариуч яки эш (хезмәт) урынындагы кадрлар хезмәте тарафыннан расланган документларның күчерелмәләре;

д) граждан хезмәтенә керешүгә яки аны үтәүгә каршы килә торган авыруларның гражданинда булмавын раслаучы документ;

е) Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында федераль законнарында каралган башка документлар.”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.Ш.Хөсәеновка йөклим.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры урынбасары – министр Р.Х.Зарипов